МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 июня 2019г. № М 242

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында нигезнамәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н. Г. Мәһдиев

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2019 елның 7 июнендәге
М 242 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хезмәткәрләрен
мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында
нигезнамә

1. Әлеге нигезнамә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә зыян килгән очракта муниципаль хезмәткәрләрнең тормышын һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе (алга таба – мәҗбүри дәүләт иминияте) буенча түләүләр очракларын, тәртибен һәм күләмнәрен билгели.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең гомере һәм сәламәтлеге муниципаль хезмәткәр вазыйфасына билгеләнгән көннән башлап муниципаль хезмәткәр вазыйфасыннан азат ителгән көнгә кадәр исәпләнә торган барлык чор дәвамында мәҗбүри дәүләт иминләштерүе узарга тиеш.

3. Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминләштерүчеләр (алга таба – иминләштерүчеләр) булып муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне уза торган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тора.

Хаким (Шәһәр Советы) аппаратында муниципаль хезмәт уза торган муниципаль хезмәткәрләр өчен иминләштерүче булып «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы» МКУ тора.

Башкарма комитетта муниципаль хезмәт уза торган муниципаль хезмәткәрләр өчен иминләштерүче булып «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» МКУ тора.

Контроль-хисап палатасында муниципаль хезмәт уза торган муниципаль хезмәткәрләр өчен иминләштерүче булып «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ тора.

4. Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминиятчеләр (алга таба – иминиятчеләр) булып мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыруга лицензияләре булган иминият оешмалары торырга мөмкин.

Иминиятчеләрне сайлап алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла

5. Мәҗбүри дәүләт иминияте килешүе (алга таба – иминият килешүе) иминләштерүче һәм иминиятче арасында иминләштерелгән зат (файда күрүче) файдасына Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә тәүлегенә 24 сәгать дәвамында иминият яклавы белән бер календарь елга төзелә.

Әлеге нигезнамәнең 7 пунктында күрсәтелгән иминият очраклары өчен иминләштерүче тарафыннан иминият килешүендә файда күрүчеләр даирәсе

билгеләнә.

Иминият килешүендә иминләштерүче тарафыннан мәҗбүри рәвештә файда күрүчеләр сыйфатында түбәндәгеләр аталырга тиеш:

1) иминләштерелгән зат вафат булган көнгә аның белән никахы теркәлгән ире (хатыны);

2) иминләштерелгән затның ата-анасы (уллыкка (кызлыкка) алучылар), иминләштерелгән затның әбисе һәм бабасы – аның ата-анасы булмаган һәм алар аны кимендә өч ел тәрбияләгән яки караган очракта;

3) иминләштерелгән затның үги атасы һәм үги анасы – алар аны кимендә биш ел тәрбияләгән яки караган очракта;

4) имнләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән яки 18 яшькә җиткәнче инвалид булган аннан өлкәнрәк балалары, шулай ук оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә белем бирү оешмаларында белем алучы, әмма 23 яшькә җитмәгән балалары;

5) иминләштерелгән зат тарафыннан опекага алынган затлар.

Файда күрүчеләр, иминләштерүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелә торган мәгълүмат нигезендә иминият килешүендә күрсәтелә. Иминият килешүендә файда күрүчеләр күрсәтелмәгән очракта, файда күрүчеләр булып граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә иминләштерелгән зат варислары таныла.

6. Төзелгән иминият килешүенең гамәлдә булу срогы чыкканга кадәр муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итү, муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгән көннән башлап, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәргә карата аның гамәлдә булуы туктатыла. Күрсәтелгән нигез буенча муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүенең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, иминиятче әлеге нигезнамәнең 12 пунктында билгеләнгән тәртиптә, әлеге муниципаль хезмәткәргә карата иминият килешүенең калган гамәлдә булу срогына пропорциональ өлешендә әлеге муниципаль хезмәткәрне иминләштерүгә бәйле түләнгән иминият премиясен иминләштерүчегә кире кайтара.

7. Иминият очраклары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт узган чорда, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда имгәнүләр, травмалар һәм авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә иминләштерелгән затның вафат булуы;

2) муниципаль хезмәт узган чорда, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда имгәнүләр, травмалар һәм авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә иминләштерелгән затка инвалидлык билгеләнү;

3) муниципаль хезмәт үткән чорда иминләштерелгән зат тарафыннан имгәнү яки травмалар алу;

4) иминләштерелгән затның медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең инициативасы буенча муниципаль хезмәткәрне билгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итеп һәм муниципаль хезмәттән җибәреп, хезмәт килешүен (контрактын) өзү

өчен нигез булган һәм инвалидлык билгеләүгә бәйле булмаган авыруга дучар булуы;

8. Иминләштерелгән затларга (файда күрүчеләргә) түләнә торган иминият суммаларының күләме, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата окладын (алга таба – оклад) тәшкил итүче, биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи окладыннан һәм класс чиннары өчен айлык өстәмә хакыннан чыгып билгеләнә.

9. Иминият очраклары барлыкка килгәндә иминият суммасы түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

1) муниципаль хезмәт узган чорда иминләштерелгән зат вафат булган очракта, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда имгәнүләр, травмалар һәм авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә – 26, 25 оклад. Күрсәтелгән иминият суммасы файда күрүчеләргә тигез өлешләрдә түләнә;

2) иминләштерелгән затка муниципаль хезмәт узган чорда, шулай ук муниципаль хезмәт узган чорда имгәнүләр, травмалар һәм авырулар нәтиҗәсендә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел эчендә инвалидлык билгеләнгән очракта:

I төркем инвалидка – 17,5 оклад;

II төркем инвалидка – 12,25 оклад;

III төркем инвалидка – 10,5 оклад;

3) муниципаль хезмәт узган чорда иминләштерелгән зат тарафыннан каты имгәнүләр яки травмалар алган очракта – җиде оклад, җиңелчә имгәнүләр яки травмалар алган очракта – 1,75 оклад. Тиешле иминият суммасы түләнә торган имгәнүләрне һәм травмаларны авыр яисә җиңелчә төргә кертү «Хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең гади һәм башлык составы затларының, җинаять-башкару системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 1998 елның 28 мартындагы 52-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән, авыр яисә җиңелчә төргә кертелгән имгәнүләр (яраланулар, травмалар, контузияләр) исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла;

4) ) иминләштерелгән зат медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең инициативасы буенча муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат итеп һәм муниципаль хезмәттән җибәреп, хезмәт килешүен (контрактын) өзү өчен нигез булган һәм инвалидлык билгеләүгә бәйле булмаган авыруга дучар булган очракта – 8,75 оклад.

Әгәр муниципаль хезмәт узган чорда яисә муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителгәннән соң бер ел үткәнче, федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесендә кабат таныклау вакытында иминләштерелгән затка инвалидлык төркеме арттырылган очракта, иминият суммасының күләме яңадан билгеләнгән инвалидлык төркеме буенча

исәпләнгән окладлар саны һәм элеккеге инвалидлык төркеме буенча исәпләнгән окладлар саны арасындагы аерманы тәшкил итүче суммага арттырыла.

Әгәр иминләштерелгән затка иминият очрагына бәйле иминият суммасы түләнгән булса, әмма иминият очрагы барлыкка килгән көннән башлап ел дәвамында һәм шуңа турыдан-туры бәйле рәвештә аның сәламәтлеге какшаса яки ул вафат булса, элек түләнгән иминият суммасын (иминият суммаларын) чигереп, өстәмә иминият түләве башкарыла.

Һәр иминләштерелгән зат өчен түләнә торган иминият премиясенең күләме иминият килешүе белән билгеләнә һәм иминләштерелгән затның иминият килешүен төзү вакытына билгеләнгән окладының 6,5 процентыннан артырга тиеш түгел.

10. Иминиятче мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминият суммасын түләүдән азат ителә, әгәр иминият очрагы:

1) иминләштерелгән затның суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый куркыныч дип танылган гамәл кылуы аркасында булса;

2) иминләштерелгән затның алкоголь, наркотик яки агулы матдәләр белән исерүенә турыдан-туры бәйле булса һәм ул суд тарафыннан расланса;

3) иминләштерелгән затның үз сәламәтлегенә белә торып зыян китерүе яки иминләштерелгән затның үзенә кул салуы нәтиҗәсендә булса һәм ул суд тарафыннан расланса.

Иминләштерелгән затның вафат булуы үзенә кул салуга китерү нәтиҗәсе булып торган очракта һәм ул суд тарафыннан исбатланса, иминиятче иминият суммасын түләүдән азат ителми.

Иминият суммасын түләүдән баш тарту турындагы карар иминиятче тарафыннан кабул ителә һәм иминият суммасын түләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән срокта, күрсәтелгән баш тарту сәбәпләрен мәҗбүри нигезле дәлилләп, язма рәвештә иминләштерелгән затка (файда күрүчегә) һәм иминләштерүчегә хәбәр ителә.

11. Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру иминләштерелгән зат (файда күрүче) гаризасы һәм иминият очрагы барлыкка килүне раслый торган документлар нигезендә иминиятче тарафыннан башкарыла.

Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карап тикшерү тәртибе иминият килешүе белән билгеләнә.

Иминият суммаларын түләү иминләштерелгән затларга иминият килешүләренең башка төрләре буенча тиешле суммаларга бәйсез рәвештә башкарыла.

Иминиятче тарафыннан иминият суммалары, иминият килешүендә билгеләнгән ысулдан файдаланып, сумнарда исәпләнгән суммаларны иминләштерелгән затларга (файда күрүчеләргә) күчерү юлы белән түләнә.

Иминият суммаларын түләү күрсәтелгән түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар алынган көннән башлап 10 көн эчендә башкарыла.

12. Иминият килешүенең гамәлдә булу срогы дәвамында иминләштерелгән затларның окладлары күләмнәре, шулай ук аларның саны

үзгәрсә, күрсәтелгән хәлләргә бәйле рәвештә алынып бетмәгән яки артык алынган иминият кертемнәре суммалары өстәмә түләнергә яисә кире кайтарылырга тиеш. Иминият килешүен төзегән якларның килешенүе буенча күрсәтелгән суммалар иминият килешүенең чираттагы гамәлдә булу чорында иминият кертемнәре күләмнәрен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминләштерүче тарафыннан иминият кертемнәрен кертүнең кабатлануы иминият килешүендә билгеләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминиятенә чыгымнарны финанслау муниципаль берәмлек бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреева